# Яшьтәш

*Мөктәп балалары өчен махсус сәхифә*


## Санкт-Петербургта 5 көн

Октябрь азагында безнең мәктәпнең VI—XI класс укучыларыннан торган группа Санкт-Петербургта экскурсиядә булды. Алдан ук әйтим, 5 көнлек бу сәяхәт анда катнашучылар күңелендә җуелмас хәтирәләр, тәэсирләр калдырды.

Петропавел крепостеның казематларында йөргәндә таш диварлар салкынлыгы тәнгә дә үтеп керде шикелле. Декабристлар утырган казематларны караганда балалар мәгълүм тарихка кабат әйләнеп кайттылар, восстание геройларын һәм корбаннарын искә төшерделәр.

Бу крепостьта аз булса да мәшһүр язучы, рус әдәбияты классигы Максим Горький да утырган. Монысы укучылар өчен игътибарга лаек яңалык булды.

Ә биредә һәр истәлекле урын—үзе бер тарих. Пискарев каберлегендә булганда күңелне тетрәндергән хатирәләр яңарды. Мемориалда ленинградлыларга сугыш чорында бирелгән икмәк, Таня Савичеваның көндәлеге куелган. Ул көндәлек битләрен укыганда дистрофиядән (ачлыктан) кырылган гаилә алга килеп басты.

Петр беренченең җәйге бакчасы гади көнкүреше безне хәйран калдырды. Император булса да зиннәт белән мавыкмаган, тыйнак кына киенгән. Ризыгы да башка күпләрнеке шикелле үк, тәлымламаган. Янәшә бүлмәдә инструментлары да саклана: акыл хезмәтеннән соң физик эшкә алына торган булган.

Сәяхәтебезнең бер көнендә Царское Селога (хәзерге Пушкин шәһәре) бардык. Аңа кадәр генә телевизордан граф де Манте Кресто турында фильм караган идек. Таныш таш диварларны күреп сөендек—фильм биредә төшерелгән булып чыкты.

Эрмитажга керүебез сәнгать дөньясының күп яңалыкларын ачты. Гасырлар буе сакланган сәнгать шедеврлары эчке, рухи дөньябызны күпкә баетты. Моннан тыш биредә 25 мең еллардан бирле саклануы мумияләрне карадык —кешелек дөньясы культурасы, истәлекләре кайчаннан бирле килүен белдек.

Исакиевск соборын да карап йөрдек. 101 метр биеклектәге башнясына күтәрелеп Санкт-Петербургны күзәттек. Күп санлы утрауларга урнашкан, йөзләрчә күперләр ярдәмендә бер-берсе белән тоташкан кала панорамасы, озын тасма булып сузылган Нева елгасы бүген дә күз алдында тора.

**Н. КӘЛИМУЛЛИНА.**
Биккол урта мәктәбе.

## *Әдәп төбе— күркәм гадәт*

Күптән түгел безгә Әлмәт авылында булырга туры килде. Автобус туктальшыннан хастаханәгә барган юлда күпме мәктәп балалары очраттык һәм һәрберсе безнең белән итәгатьле итеп исәнләшеп уздылар. Безнең үзебезнең авылда да, башка җирдә дә мондый тәрбиялелекне очратканыбыз булмады. Ә биредә исә балаларны өлкәннәргә ихтирам билгесе күрсәтү кебек төшенчә сүздә генә калмаган, бәлки күркәм гадәткә әйләнгән. Әлбәттә, монда аларның әти-әниләренең дә, мәктәп укытучыларының да тырышлыгы мактауга лаек. Бу электән килгән һәрбер кешене ачык йөз белән сәламләү, аңа исән-иминлек теләү кебек гадәт беренче карашка гади генә тоелса да аның төбендә кешенең югары әхлаклыгы, кешелелеге ятуын онытмыйсы иде. Кешенең холкы да шул кечкенә гадәтләрдән формалаша ич. Шуңа күрә әлмәтлеләрнең бу мактаулы үрнәкләре башка авылларга да таралсын иде.

**Л. ЕГРАШКИНА,**
**А. ЧАЛОВА.**
Сәләнгеш авылы.

Мәскәү малае Савелий Косенко 11 яшендә Мәскәүнең иң авыр университетларыннан берсе—Мәскәү югары техник университеты студенты булды.

Гади генә күренгән бу малайга карасаң, аның киеренке акыл хезмәте белән шөгыльләнүен күз алдына китерүе дә кыен. Дүрт яшендә ул укый, өчтә ирекле рәвештә дүрт арифметика гамәлен белә иде. Биш яшендә Жюль Вернны укып чыга, ә җидедә өйдәге компьютерда программалар төзи. Барлык балалар кебек мәктәпкә керергә вакыт җиткәч, ул анда кермичә генә бишенче класс өчен имтихан тапшыра. Ун яшендә мәктәпне тәмамлый.



Савелийның әнисе Елена Борисовна—белгечлеге буенча математик-программист. Үз баласыннан вундеркинд ясарга ул һич тә омтылмый. Бары тик аның табигый кызыксынучанлыгын канәгатьләндереп үзе белгәнне генә тапшыра иде. Баласын бернинди бакчага, мәктәпкә бирмичә, үзе бердәнбер укытучысы да, тәрбиячесе дә була. Ярый әле туганнары, ире Валентин Савельевич (ул Мәскәү ВУЗларының берсендә физика дәресләре алып бара) моңа каршы төшмиләр. Ә хәзер Савелий мөстәкыйль, студент тормышы белән яши. Тик бернәрсә борчый ананы: университетка йөрергә ерак,ә Савелий бәләкәй.

**Рәсемдә: Савелий әнисе белән.**

## Мәктәптән — бакчага

Балалар музыка мәктәбендә 230 лап бала белем ала. Биредә шулай күнелде инде: ел саен алар район культура йортында отчет концертлары белән чыгыш ясыйлар, шунда күп халыкка мәктәптә алган белемнәрен, сәләтләрен күрсәтәләр. Бу гына түгел, тагын бер чараны традициягә керттеләр алар. Ел саен яз көннәрендә «балалар музыка атн а л ы г ы » көннәрендә яшь башкаручылар мәктәпләрдә, балалар бакчаларында концертлар куеп үткәрәләр. Быел вакыттан бераз тайпылыш ясалды: алар аны көзге каникуллар чорында уздырдылар. Малайлар, кызлар икенче мәктәптә «Әкият», «Теремок», «Тиенкәй» бакчаларында булдылар. Алар анда домра, фортепьяно, баянда рус, совет һәм татар композиторлары иҗатын башкардылар. Нәниләр өчен аларның килүе үзе бер бәйрәмгә әйләнде.

**Ф. ВӘГЫЙЗОВА.**

## Хыял гына сүнмәсен

Нефтьчеләр поселогында «Яшьтәш» клубы быел инде дүртенче елын эшли.

— Клуб ачылганнан бирле эшләүчеләрдән директор да, мин дә, идән юучы гына калды инде, — ди агачка бизәк төшерү түгәрәген алып баручы В.С. Малыгин. Сәбәбен дә аңлатты ул: яшүсмерләр белән эшләү авыр, түләү бик аз, хәер болары әле ярты бәла гына, иң мөһиме — шөгыльләнергә материаллар, инструментлар, приборлар җитмәве башлаган эшне ташларга мәҗбүр итә.

Владимир Сергеевич үз башына төшкәнне сөйли иде. Быелга кадәр ул техник иҗат түгәрәген алып барды. Түгәрәк районда беренче урынны алып торды, малайлар бик теләп йөрделәр. Ләкин алда әйтелгәнчә килеп чыккач, алар агачка бизәк төшерү эшенә керешкәннәр. Түгәрәккә йөрергә теләүчеләр бик күп. Һәр занятиегә тенә 30лап яшүсмер килә. Инде беренче хезмәтләре дә бар: алар — яктырткычлар (светильник), кашыклар, панно һәм башкалар. Материал кайдан алалар соң? Ә кайдан нәрсә алырга мөмкин, бигрәк тә производство калдыклары ташланырга тиешле әйберләр алар өчен иң кирәкле материал да инде. Һичшиксез Владимир Сергеевичның «һәр оешма, предприятие кирәксез материалларын, яшүсмерләр клубларына бирсеннәр иде», дигән тәкъдиме, эшлекле һәм балалар өчен файдалы.

НГДУ, теш л ә р е н кысып булса да, аларга өч электропычкы сатып ала. Түгәрәк җитәкчесе тагын өчне ничек тә үзләре эшләп алу турында уйлый. Моңа мөмкинлекләр булырмы, анысын вакыт күрсәтер. Киләчәктә алар ипи савытлары, декоратив элгечләр, люстралар ясарга хыялланалар.

Малайлар өчен тагын бер сөенеч булды әле соңгы көннәрдә: «Яшьтәш»тә радио сөючеләр түгәрәге эшли башлаячак. Клуб директоры С. Ф. Захарова моны ишетүче малайларның хәтта ур-ра кычкыруларын сөйли.

«Яшьтәш» клубы 4 нче мәктәптә укучылар өчен кичке кафе хезмәтен дә үти. Алар еллар буе төзелүче «Яшьләр йорты»ның төзелеп бетүенә ышанычларын югалтканнар, күрәсең. Биредә класслары белән туган көннәр уздыралар. Ризыклар, савыт-сабаларны үзләре ташыйлар, ә Светлана Федоровнага уеннар оештыру гына кала.

С. Ф. Захарованың күптәнге хыялы һаман да күңелендә яши әле: ул — курчак театры ачу. Әмма тагын башта язылган проблема юлны кисеп тора: курчаклар юк. Шулай да нык булыгыз, Светлана Федоровна, хыял, энтузиазм сүнмәсә, кайчан да булса курчаклары булыр.

**Ф. ГАЛИМОВА.**



Авыл малае мин. Шәһәр малайлары әле тәмле төш күреп йоклап яткан чакта, без инде эти белән фермага атлыйбыз. Чөнки эти белән әни ферма сыерларын арендага алдылар. Ә мин аларга булышам.

Мин малкайларга ашарга таратышам. Ә алар шундый зирәкләр — утарга якынлашканны күрүгә, сәлам биргәндәй мөгрәп каршы алалар. Шушындый дусларым булганга күңелем дә шат минем.

## Көлдергечләр

Кызы укудан кайткач, әнисе сораган:

— Кызым, нишләп битең ап-ак төскә кергән?

Кызы көлемсерәп:

— Әни, кыш җитте бит инде, минем битемне дә Кыш бабай ак төскә буяды.

**Г. ЛОТФУЛЛИНА.**

x x x

Тыны кабып кайтып кергән улына әнисе:

— Әллә физкультура укытучыгыз бик каты чаптырдымы? — ди.

— Юк ла, үзем чаптым. Тәнәфестә йокыга кителгән төшемдә юлбарыс күрдем. Ул мине ашарга килә, имеш. Йокыдан уяндым да, юлбарыс кабып йотмасын дип, өйгә элдерттем, — ди малай.

**Р. ГОМӘРОВА.**

# Яшьтәш

*Мәктәп балалары өчен махсус сәхифә*

## *Санкт-Петербургта 5 көн*

Октябрь азагында безнең мәктәпнең VI—XI класс укучыларыннан торган группа Санкт-Петербургта экскурсиядә булды. Алдан ук әйтим, 5 көнлек бу сәяхәт анда катнашучылар күңелендә җуелмас хатирәләр, тәэсирләр калдырды.

Петропавел крепостеның казематларында йөргәндә таш диварлар салкынлыгы тәнгә дә үтеп керде шикелле. Декабристлар утырган казематларны караганда балалар мәгълүм тарихка кабат әйләнеп кайттылар, восстание геройларын һәм корбаннарын искә төшерделәр.

Бу крепостьта аз булса да мәшһүр язучы, рус әдәбияты классигы Максим Горький да утырган. Монысы укучылар өчен игътибарга лаек яңалык булды.

Ә биредә һәр истәлекле урын — үзе бер тарих. Пискарев каберлегендә булганда күңелне тетрәндергән хатирәләр яңарды. Мемориалда ленинградлыларга сугыш чорында бирелгән икмәк, Таня Савичеваның көндәлеге куелган. Ул көндәлек битләрен укыганда дистрофиядән (ачлыктан) кырылган гаилә алга килеп басты.

Петр беренченең җәйге бакчасы гади көнкүреше безне хәйран калдырды. Император булса да зиннәт белән мавыкмаган, тыйнак кына киенгән. Ризыгы да башка күпләрнеке шикелле үк, талымламаган. Янәшә бүлмәдә инструментлары да саклана: акыл хезмәтеннән соң физик эшкә алына торган булган.

Сәяхәтебезнең бер көнендә Царское Селога (хәзерге Пушкин шәһәре) бардык. Анда кадәр генә телевизордан граф де Манте Кресто турында фильм караган идек. Таныш таш диварларны күреп сөендек — фильм биредә төшерелгән булып чыкты.

Эрмитажга керүебез сәнгать дөньясының күп яңалыкларын ачты. Гасырлар буе сакланган сәнгать шедеврлары эчке, рухи дөньябызны күпкә баетты. Моннан тыш биредә 25 мең еллардан бирле саклануы мумияләрне карадык — кешелек дөньясы культурасы, истәлекләре кайчаннан бирле килүен белдек.

Исакиевск соборын да карап йөрдек. 101 метр биеклектәге башнясына күтәрелеп Санкт-Петербургны күзәттек. Күп санлы утрауларга урнашкан, йөзләрчә күперләр ярдәмендә бер-берсе белән тоташкан кала панорамасы, озын тасма булып сузылган Нева елгасы бүген дә күз алдында тора.

**Н. КӘЛИМУЛЛИНА.**

Биккол урта мәктәбе.

## *Әдәп төбе — күркәм гадәт*

Күптән түгел безгә Әлмәт авылында булырга туры килде. Автобус тукталышыннан хастаханәгә барган юлда күпме мәктәп балалары очраттык һәм һәрберсе безнең белән итәгатьле итеп исәнләшеп уздылар. Безнең үзебезнең авылда да, башка җирдә дә мондый тәрбиялелекне очратканыбыз булмады. Ә биредә исә балаларны өлкәннәргә ихтирам билгесе күрсәтү кебек төшенчә сүздә генә калмаган, бәлки күркәм гадәткә әйләнгән. Әлбәттә, монда аларның эти-әниләренең дә, мәктәп укытучыларының да тырышлыгы мактауга лаек. Бу электән килгән һәрбер кешене ачык йөз белән сәламләү, аңа исән-иминлек теләү кебек гадәт беренче карашка гади генә тоелса да аның төбендә кешенең югары әхлаклыгы, кешелелеге ятуын онытмыйсы иде. Кешенең холкы да шул кечкенә гадәтләрдән формалаша ич. Шуңа күрә әлмәтлеләрнең бу мактаулы үрнәкләре башка авылларга да таралсын иде.

**Л. ЕГРАШКИНА,**
**А. ЧАЛОВА.**

Сәләнгеш авылы.

Мәскәү малае Савелий Косенко 11 яшендә Мәскәүнең иң авыр университетларыннан берсе — Мәскәү югары техник университеты студенты булды.

Гади генә күренгән бу малайга карасаң, аның киеренке акыл хезмәте белән шөгыльләнүен күз алдына китерүе дә кыен. Дүрт яшендә ул укый, өчтә ирекле рәвештә дүрт арифметика гамәлен белә иде. Биш яшендә Жюль Вернны укып чыга, ә җидедә өйдәге компьютерда программалар төзи. Барлык балалар кебек мәктәпкә керергә вакыт җиткәч, ул анда кермичә генә бишенче класс өчен имтихан тапшыра. Ун яшендә мәктәпне тәмамлый.



Савелийның әнисе Елена Борисовна — белгечлеге буенча математик-программист. Үз баласыннан вундеркинд ясарга ул һич тә омтылмый. Бары тик аның табигый кызыксынучанлыгын канәгатьләндереп үзе белгәнне генә тапшыра иде. Баласын бернинди бакчага, мәктәпкә бирмичә, үзе бердәнбер укытучысы да, тәрбиячесе дә була. Ярый әле туганнары, ире Валентин Савельевич (ул Мәскәү ВУЗларының берсендә физика дәресләре алып бара) моңа каршы төшмиләр. Ә хәзер Савелий мөстәкыйль, студент тормышы белән яши. Тик бернәрсә борчый анаены: университетка йөрергә ерак, ә Савелий бәләкәй.

**Рәсемдә: Савелий әнисе белән.**

● Пионер тормышы яңалыклары

## Галстугың кинди булыр?

**Район пионерлар йортында өлкән пионервожатыйлар семинары үтте. Алар биредә балалар хәрәкәте, пионерлар тормышы, киләчәктә ничек итеп кызыграк яшәү турында сөйләшү алып бардылар.**

Шуннан иң мөһимнәре:

ПИОНЕР ГАЛСТУГЫ. Ул элеккечә бертөрле генә түгел, ә укучылар теләгәнчә үзгәртелергә тиеш. Әйтик, яртысы яшел, икенче яртысы зәңгәр. Яшел—яшеллек, табигать символы, ә зәңгәр—күк төсе. Зәңгәр һәм кызыл—кызыл элеккечә кан төсен түгел батырлык төсен аңлата, ә галстук тулысынча күк йөзен, җирне саклау турында сөйли. Ә табигатьне саклаучыларга яшел галстук йөртергә мөмкин булачак. Шулай итеп галстукны шөгыльләре, мавыгуларына карап йөртергә рөхсәт ителәчәк. Әлбәттә, бу очракта балаларның фантазиясе бик бай булырга тиеш.

Семинарда бу тәкъдимгә кушылырга теләмәүчеләр ягъни кызыл галстукны үзгәртмәскә дигән фикерне яклаучылар да булды.

ЭМБЛЕМА белән дә шундый ук хәл, пионерлар үз отрядларына эмблемаларны шөгыльләренә хас итеп ясыйлар. Мәсәлән, балалар берләшмәләре федерациясенең эмблемасы шыксыз үрдәк баласы. Әлбәттә киләчәктә ул гүзәл аккошка әйләнәчәк дигән исәп тотыла. Ә Татарстан варис-пионерлары эмблеманы үзләре сайлый ала.





Яшь «артист»лар сәхнәгә чыгарга әзерләнә.

● Пионер тормышы яңалыклары

ПРОГРАММА. Балалар хәрәкәтенең класстан тыш һәм мәктәптән тыш эшчәнлеге өчен төрле төрдәге программалар тәкъдим ителә. «Демократик культура мәктәбе», «Балаларның шәфкатьлелек ордены», «Тормыш агачы»—болар барысы да старт программалар. Алардан тыш «Уен—җитди эш», «Авыл лицее», «Үз эшемне башкарырга телим», «Ал җилкәннәр», «Дөньяны матурлык коткара», «Үз тавышым» дигән исем астында программалар бар. Билгеле инде, аларның җисеме исемнәренә туры килергә тиеш.

Семинарны оештыручы—пионерлар йорты хуҗалары пионервожатыйларга бүләк итеп төрле чаралар үткәрергә ярдәм булырлык сценарийлар, эмблемалар бирделәр.



# Укучылар иҗаты

## Төнбоек

Борын-борын заманда куе һәм яшел урман аланында дуслары белән бер чәчәк яшәгән. Бал кортлары аның таҗына утырсалар, ширбәтен эчми китмәгәннәр. Бервакыт бу аланга җиләк җыючылар килгәннәр. Алар чәчәкләрне таптаганнар, өзгәннәр.

Кич җиткән. Чәчәк кызы шыпырт кына урман янындагы күлгә киткән. Күл эчендә дә чәчәкләр үсә икән. Безнең чәчәк тә алар янында калырга рөхсәт сораган. Күл чәчәкләре аңа үзләре янында яшәргә рөхсәт иткәннәр. Монда аңа яхшы булса да, төн җиткәч, иптәшләрен сагына, боега икән ул. Шуңа күрә аны төнбоек дип йөртәләр ди, имеш.

**Алсу ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.**

## Күке ничек үрдәкне акылга утырта

Көннәрдән бер көнне үрдәк, күкене очрата да, зарлана башлый:

—И, күке дус, менә ничә көннәр инде саескан авылга очып килә дә, такылдый башлый. Аны тыңлап колакларыбыз чукракланып бетте,—ди икән.

Ә күке аңа:

—И үрдәк дус, син саескан да, саескан дисең. Ә саескан килә дә очып китә бит ул. Ә менә син очып китмисең. Син кемнәрнең колакларын чукракландырдың икән?—дигән.

—Булмас сиңа! Минем үзем. Үрдәк бер сүз дә әйтмәгән, тиз генә авылга, өенә киткән. Шулай итеп, күке үрдәкне акылга утырткан ди.

**Э. НИГЪМӘТҖАНОВА.**

# Матурлык дөньясында

МАТУРЛЫК балаларга эстетик тәрбия генә биреп калмый, хәтта уйлау, фикерләү сәләтен дә арттыра. Уен моментларын гына алыйк. Квадрат, яисә әйләнә ясап йөрергә кирәк икән идәнгә төшерелгән чәчәкләр ориентир булалар, димәк, квадратның ниндиерәк буласын күз алдына китерергә ярдәм итәләр.

«Әкият» балалар бакчасының мөдирен алыштыручы Людмила Игнатьевна Сергеева бу сүзләрне музыка залына кергәч сөйли. Бу зал хохлома бизәкләре белән үзенчәлекле: түшәмнәрдә, урындыкларда, идәндә, хәтта кәрнизләргә дә хохлома бизәкләре төшерелгән. Хәер, бу олы бакчаның бинасында һәр гомуми бүлмә, зал, хәтта ике озын баскыч та һәркайсы үзенә бер төрле бердәм стиль белән эстетик баетылган. Вестибюль һәм бер баскыч мозаика белән бизәлгән.

—Мозаиканы белгечләр ясады. Без уйладык та, ничек булса да шуңа охшаш бизәкләр белән баетуны кирәк санадык, —ди Людмила Игнатьевна.

Бу өстәмәләрне төрле әкиятләрдән персонажлар, төрле күренешләр тәшкил итә. Рәсемнәр, бизәкләр төшерү белән дә Л. И. Сергеева һәм методист Зинаида Николаевна Гук шөгыльләнгәннәр. «Четрекле эш, әмма балаларга да, үзебезгә дә күпме шатлык алардан»,—диләр алар.

Икенче баскычтан татар орнаметыннан аппликацияләр озата бара. «Рәсем сәнгате студиясе» дип аталган кечкенә бүлмәдә бөтен җиһазлар да Гжель стиле белән бизәлгән. Һәр бушлык урында берәр төрле күргәзмә үткәрелә. Әйтик, рәсемнәр күргәзмәсе ел фасылы саен үзгәреп тора, хәзерге вакытта анда «Көз». «Туган ягым, яратам сине», кипкән яфраклардан, чәчәкләрдән оештырылган «Табигать һәм фантазия» күргәзмәләре, бер баскыч астында ял итү, икенче төрле әйтсәк табигать почмагы балаларга тәрбия бирү, матурлыкны, табигатьне, кеше хезмәтен күрергә өйрәтүдә зур ярдәм, әлбәттә.



«Әкият» балалар бакчасы 300 урынга исәпләнгән булса да, хәзер анда 400ләп бала йөри. Сүз дә юк болай да артык зур бакча,өстәвенә кыссанга да әйләнгән. Группаларда 30—35 бала. Билгеле, шулкадәр бала белән төрле уеннар оештыру да, аларга күнекмәләр бирү дә ифрат кыенга туры килә. Шулай да биредә бу максатлар өчен башка юллар эзлиләр. Быел икенче ел инде бакчада төрле мавыгулар буенча түгәрәкләр, секцияләр ачылган, аларга бер вакытта бишәр генә бала йөри.

Түгәрәкләрдән әлегә иң күренеклесе: «Аланчык» табигать почмагы дияр идем мин. Биредә әрлән, ташбака, керпе, попугай, бүлмә гөлләре һәм башкалар бар. Балалар алар белән танышу гын түгел, тәрбияләү, үстерү күнекмәләрен дә алалар. Әлбәттә һәр бала,, шул исәптән тәрбияче— түгәрәкне алып баручы да күңеленә якын шөгыльне сайлаган. Әйтик, рәсем ясауга осталар «Салават күпере» студиясенә йөриләр. Шулай ук рәхәтләнеп «Казачок» биюләр түгәрәгенә, «Әкият» музыкаль театрына, «Батыр» физкультура секциясенә, «Умарта корты» дип аталган кул хезмәте түгәрәгенә йөрергә мөмкин. Аларның һәркайсы диярлек үз күргәзмәләрен дә оештырырга өлгергән инде. Биредә бүлмәләр искиткеч тыйнак, матур, зәвык белән бизәлгән. Әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирерлек приборлар, уенчыклар, компьютерлар да юк, барысы да гади. Әмма Людмила Игнатьевна әйткәнчә, бакча мөдире Римма Гәрәевна Карымова тырышлыгы аркасында авыр заманга кадәр иң кирәкле җиһазлар, тукыма һәм башкалар тупланып калына. Ә хәзергә кул астында нәрсә бар, шуны балаларны тәрбияләү өчен файдалы итәргә тырышалар. Ә бит нәкъ шул яшьтә яхшы тәрбия бирү зарур да. Мәктәп вазифасына шуны тулыландырырга гына кала.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

**Рәсемдә: —Ай, бигрәк каты икән бу! «Әкият» балалар бакчасында яшь тәрбияче Жанна Владимировна Боева балаларны ташбака белән таныштыра.**

**Н. Квашнина фотосы.**

## ИШЕТМӘСӘҢ ИШЕТ

Ике малай сөйләшә:

—Кайсыбер этләр хуҗаларыннан да акыллырак булалар.

—Каян беләсең? Булмас, малай.

—Булмас сиңа! Минем этем шундый...

x x x

Синең песиең бигрәк әйбәт. Бездә тычканнар күп, песиеңне бер көнгә миңа биреп тор әле.

—Юк инде, тычканнарыңны безгә алып кил...

x x x

Шәһәр малае:

—Әти, ничә төрле сөт була?

—Гади, майсызландырылган, куертылган. Сиңа нәрсәгә кирәк соң ул, улым?

—Мин сыер рәсеме ясыйм. Аның ничә имчәге барлыгын төгәл белергә кирәк миңа...